СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның 28 апреленнән №20

«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 28 декабрендәге 562-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 31 декабрендәге 109- ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

36 статьяның 5 өлешендәге 2 пунктында «Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар - Урдаласы авылы, Совет урамы, 98 йорт административ бинада, Совет урамы, 103 йорт мәдәният йорты бинасында, Карагай авылы, Тельман урамы, 31 йорт КФҮ бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) “Авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Г.Ә.Әхмәтова